**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НИЖНЕКАРМАЛКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423102, СЕЛО НИЖНЯЯ КАРМАЛКА,
УЛ.ЛЕНИНА, Д.44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423102, ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛЫ,
ЛЕНИН УРАМЫ, 44нче ЙОРТ

Тел.: (84396)2-39-47 ФАКС: (84396) 2-36-47

Email: Nkar.Cmn2@tatar.ru

№ 147 16.12.2019

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының
2013 елның 15 ноябрендәге 60 номерлы
«Җир салымы турында» карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 142 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 60 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 60 номерлы «Җир салымы турында» Карарына (авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 80 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 96 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2 статьяда:

- 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: « 1) 0,3% авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллануы зоналары составында булган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җирләргә карата;
- 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «2) 0,3% торак фонд һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына кагылмаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);
- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «4) 0,15% шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм

Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата»;

- 5 пунктны төшереп калдырырга.
- 6 пунктны 5 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасының 2-4 абзацы нигезләмәләре 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә, әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасының 5 абзацы 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылып чыккан көннән бер ай үткәннән соң.

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Түбән Кармалка авыл җирлеге
Советы рәисе урынбасары, башлыгы урынбасары Е.Н. Денисова